**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТЕЛӘЧЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
**(IV чакырылыш)**

# КАРАР
**чираттан тыш утырыш**

**27 ноябрь 2023 ел** **№ 113** **Теләче ав.**

**Физик затлар мөлкәтенә салым турында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге нигезендә, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясендә мәҗбүри түләүгә физик затлар мөлкәтенә салымны билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Түбәндәге күләмдә салым ставкаларын билгеләргә:

1) түбәндәгеләргә карата 0,1 процент:

мәйданы 30 квадрат метрдан артмаган һәм исемлеккә кертелгән салым салу объектында урнашкан гараж һәм машина урыны, Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты, Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 10 пунктының икенче абзацында каралган салым салу объекты нигезендә билгеләнә;

хуҗалык корылмалары яисә корылмалар, аларның һәркайсының мәйданы 50 квадрат метрдан артмый һәм алар шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, дача хуҗалыгы, яшелчәчелек, бакчачылык яисә индивидуаль торак төзелеше өчен җир кишәрлекләрендә урнашкан;

2) түбәндәгеләргә карата 0,2 процент:

фатирлар;

бүлмәләр;

3) түбәндәгеләргә карата 0,3 процент:

торак йортлар;

мондый объектларның проектланган билгеләнеше торак йорт булса, төгәлләнмәгән төзелеш объектлары;

составына бер генә торак урыны (торак йорт) булса да керә торган бердәм күчемсез комплекслар;

4) түбәндәгеләргә карата 2 процент:

Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектлары;

Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 10 пунктының икенче абзацында каралган салым салу объектларына, шулай ук

һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан арткан салым салу объектларына карата;

5) салым салуның башка объектларына карата 0,5 процент;

3. Түбәндәге категориядәге гражданнар өчен салым льготасы билгеләргә:

А) "Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация турында" 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә (алга таба-хәрби хезмәткәрләр) мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлеге территориясендә яшәүче Россия Федерациясе гражданнарын һәм аларның гаилә әгъзаларын мөлкәтенә салым түләүдән азат итәргә.

Хәрби хезмәткәрләрнең гаилә әгъзалары дигәндә түбәндәгеләр аңлашыла:

1) хәрби хезмәткәр белән никахта торучы (торучы) ир яисә хатын;

2) хәрби хезмәткәрләрнең 18 яшькә җитмәгән яисә бу яшьтән өлкәнрәк балалары, әгәр алар 18 яшькә җиткәнче инвалид булган булсалар, шулай ук көндезге уку рәвешендәге мәгариф оешмаларында белем алучы балалар - уку тәмамланганчыга кадәр, әмма алар 23 яшькә җиткәннән дә соңга калмыйча;

3) хәрби хезмәткәрнең ата-анасы.

Салым ташламасы Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы территориясендә урнашкан һәр төр салым салуның бер объектына карата салым түләүче сайлавы буенча салым ташламаларын куллану нигезләре санына карамастан бирелә.

Салым льготасы Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясендә даими яшәүче салым түләүчеләргә салым түләүче милкендә булган һәм эшкуарлык эшчәнлегендә кулланылмый торган салым салу объектына карата салым суммасы күләмендә бирелә.

Б) 18 яшькә кадәрге өч һәм аннан да күбрәк баласы булган гражданнарны мөлкәтекә салым түләүдән азат итәргә.

Әлеге пунктның Б пунктчасында күрсәтелгән гражданнарның балаларын мөлкәтекә салым түләүдән азат итәргә.

Салым льготасы күпбалалы гаиләгә туры килә торган салым салуның бер объектына карата салым түләүченең сайлавы буенча бирелә. Салым льготасы Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясендә даими яшәүче салым түләүчеләргә салым түләүче милкендә булган һәм эшкуарлык эшчәнлегендә кулланылмый торган салым салу объектына карата салым суммасы күләмендә бирелә.

Салым льготасы салым салу объектларының түбәндәге төрләренә карата бирелергә мөмкин:

1) фатир, фатирның бер өлеше яисә бүлмә;

2) торак йорт яисә торак йортның бер өлеше.

4. Үз көчен югалткан дип танырга:

- Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлеге Советының 2014 елның 27 ноябренең №161 номерлы «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» карары;

- Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлеге Советының 2015 елның 16 июненең №188 номерлы «Татарстан

Республикасы Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлеге Советының 2014 елның 27 ноябренең №161 номерлы «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» карарына үзгәрешләр кертү турында» карары;

- Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлеге Советының 2015 елның 16 июненең №4 номерлы «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлеге Советының 2014 елның 27 ноябренең №161 номерлы «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» карарына үзгәрешләр кертү турында» карары;

- Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлеге Советының 2018 елның 21 февраленең №88-2 номерлы «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлеге Советының 2014 елның 27 ноябренең №161 номерлы «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» карарына үзгәрешләр кертү турында» карары;

- Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлеге Советының 2018 елның 29 ноябренең №116 номерлы «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлеге Советының 2014 елның 27 ноябренең №161 номерлы «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» карарына үзгәрешләр кертү турында» карары.

5. Әлеге карарның 3 пунктындагы А пунктчасының гамәлдә булуы физик затлар мөлкәтенә салымны 2021-2022 елның салым чорларына исәпләүгә бәйле хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

6. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.

7. Әлеге карар 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Теләче муниципаль районы
Теләче авыл җирлеге башлыгы Н.Н. Хаҗипов